# МӨГРИ-МӨГРИ КИЛӘ БӨЙРӘКӘЙ

Роман



# БЕРЕНЧЕ КИТАП*

## Беренче бүлек

Иртәнчәкләй торып, тышка чыксам,
Мөгри-мөгри килә Бөйрәкәй.
Бөйрәкәйне сауган шул кызны уйлап
Өзелә шул минем үзәккәй...

— Аптыраттың әле син, Мәдинә, — Гөлбану әллә тотеннән, әллә моңнан яшьләнгән күзләрен кызына төбәде, — кемнән отып алдың син бу җырны, ә?!

— Әллә тагын... — Кыска гына күлмәк кигән какча гәүдәле кыз урыныннан сикереп торды, нәзек кенә беләкләрен, беләкләре кебек үк нечкә аякларын тирәякка болгап, күнегүләр ясый башлады: — Бер, ике, өч!

— Иплэп, энеләреңне уятырсың! Ай, ата Габидә!..

«Ата Габидә» димәслек тә түгел иде Мәдинәне шушы минутта: нәкъ малайлар кебек. Менә кызларга гына хас шаянлык белән очкынланган шомырттай күзләре һәм яңа туган айдай сызылып киткән кашлары булмаса, кем ышаныр иде икән аның кыз бала булуына?

Гөлбану мич буена чүгәләгән җиреннән торгач та кызына һаман текәлеп каравында булды: тал чыбыгыдай нечкә үзе, эчендә җаны ничек тора, ә тавышы, моңы... Шушындый моңның гап-гади бер баладан чыгуына ышанырлык та түгел.

Гөлбану үзалдына тирән көрсенде дә чөйдәге кыска тунына үрелде:

— Фермага китәм инде мин, балам. Күмер төшкәч, казандагы суны самавырга салырсың. Кайнап чыкса, басып куй — мин озакламам. — Әнисенең соңгы сүзләре

---

* Пенталогиянең беренче китабы. Әлеге романы өчен автор Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

инде чоланга чыккач ишетелде: — Абзарны карап тор — сыерның суы киткән бүген! Энеләреңне күзеңнән югалтма — самавырга пешмәсеннәр!

Мәдинә исә, әнисе әйтмәсә дә, сыер янына чыгарга гына тора: бозау дөньяга киләчәк бүген! Мәдинә аңа Бөйрәкәй дип исем кушачак. Әлеге җырын да бит ул шуңа җырлады.

* * *

Иңбашына бишмәт салган, аягына әнисенең тирән галошын кигән Мәдинә абзар ишеге төбенә җиткәч куркыбрак калды. Эчтә өзек-өзек мышнап тын алган тавышны ишеткәч, тагы да ныграк каушады.

— Билдәш! — Үз исемен ишетү белән гадәттә мөгрәп куя торган сыер бу юлы эндәшмәде. — Билдәш, сиңа әйтәм! — Мәдинә, әллә салкыннан, әллә дулкынланудан тыңлаусызга әйләнгән бармакларын көчкә кыймылдатып, ишекнең бавын чиште, сак кына басып, түргә, сыер яткан якка узды. — Билдәшкәй…

Билдәш янә тавыш бирмәде. Мәдинәнең, әлбәттә, сыер бозаулаганын күргәне бар, тик анда, фермада, әнисе, башка өлкән кешеләр була. Өйдән чыкканда бозаулап яткан сыерны күреп, болай каушармын, куркырмын дип уйламаган иде ул. Мәдинә сыер тизәге белән сыланган, хәзер инде төрле-төрле җирдән кубып төшә башлаган читән абзарның ярыгы аша эчкә карады. Аның күзләре туптуры сыер күзләре белән очрашты. Йа Рабби… Хайван күзләренә чыккан өнсез газап менә-менә шартлар да гүя күзе белән бергә атылып чыгар төсле. Йа Ходай, ярдәм итә күр Билдәшкә! Мәдинә йөрәге дерт-дерт типкән килеш эчкә үтте һәм Билдәш янына чүгәләде:

— Тәңрем… Аллам… Ходаем!.. — Билдәшнең хәлен җиңеләйтә торган догалар булса, шушы минутта Мәдинә аларның меңен берьюлы кабатлар иде. — Әни, әнкәем… Әни! — Ул хәзер фермага йөгерер иде, Билдәшне бу хәлдә ничек ташлап китсен?!

Өстенә каплаган бишмәте күптән инде шуып төшеп күлмәкчән калган кызыкай, кинәт бер катгый карарга килгәндәй, гәүдәсен турайтты, аннан ашыкмый гына, әнисенә охшатырга тырышып, әкрен басып, сыер янына килде дә тулгак газабында тартышкан җан иясенең арт санына кулын салды. — Билдәш, җаным, әйдә инде, тыныш!

Печән җитмәүдән күтәрәмгә калган сыер авыр бозаулады. Мәдинә терсәгенә тиклем канга буялып, сыерга бозауларга булышты. Бозауның арткы тояклары карыннан аерылганда, Мәдинә, үзе дә хәлсезләнеп, аркасы белән туң җиргә чалкан төште. Сыер урыныннан торырга маташып карады, ләкин көче җитмәде, кире ятты, аннан, мөгрәп, бозавын күрергә теләп, башын артка борды.

— Хәзер, сабыр ит… — Мәдинә канлы-сүлле юеш җан иясен ничек итсә итте, әнисе алдына салды. — Әниең ул синең, бозаукай, әниең…

Билдәш ач хайван комсызлыгы белән бозавын ялаган арада, бер кочак печән күтәреп, Мәдинә өйгә керде дә сүрелгән учакның җылысы төшкән урынга шул печәнне түшәде.

— Апай… — Уянып, мыгырданырга уйлап яткан энеләренә боерулы тавыш белән:

— Тыныгызны чыгармагыз! — диде дә тагы тышка атылды. Хәзер үк өйгә кертмәсә, бозау бит өшер, туңып бетәр. Мәдинә үзенең җилкәсеннән шуып төшеп калган бишмәтен табып бозауны салды да, баласы артыннан кузгалырга маташкан Билдәшнең йөрәкне әрнетеп мөгрәвенә карамый, теше-тырнагы белән көчәнеп, бозау яткан бишмәтне өйгә таба өстерәде…

* * *

Кич булды. Мәдинә, дәреслекләрен алып, учакта янган утка якын килеп утырды. Гөлбану мич алдында, бүкән өстенә тас куеп, көл суында Мәдинәнең, үзенең керләрен юа. Ут аның озынчарак нәфис яңакларын, куе керфекләре арасыннан томрап торган күзләрен яктырта. Матур шул Мәдинәнең әнисе, яшь.

— Әни, хәзер сиңа ничә яшь ул?

Гөлбану авыз чите белән генә көлемсерәде:

— Әниеңнең яше нигә кирәк булды, кызым?

— Болай гына, — Мәдинә, җылыда изрәп йоклаган бозауны уятудан куркып, шыпыртын гына сөйләүгә күчте, — мин туганда сиңа уналты гына яшь булганмы ул, әни?

— Шулай гына иде шул, балам.

— Уй! — Мәдинә кинәт тетрәнеп, күзләрен йомды. — Ә мин, әни, кияүгә бер дә чыкмаячакмын!

— Һы… Кызык икән…

— Әни, әтием... Ул кайтса... — Мәдинә кинәт үз уеннан үзе оялгандай тотлыкты.

— Нәрсә... әтиең?

— Болай гына... Ул кайтса, сиңа кыен булмас иде дигән идем...

— Сиңа түгел, безгә диген...

— Бозаукаебыз матур, әйе бит, әни? — Мәдинә әтисе турындагы сүзне тиз генә икенчегә борырга тырышты. Әнисеннән ул бөтенләй икенче нәрсә: «Нигә син Урыс Һашимга кияүгә чыктың?» — дип сорамакчы иде.

* * *

Читкә какканын хәтерләми Мәдинә әтисенең. Эчүен эчте. Әле ул чакта, сугышка тиклем, авылда салгалаган ирләр булса да, Һашим кебек котырганчы эчеп йөргәннәре юк иде. Базаргамы, он тарттырырга барсынмы — Һашимның аек кайтканы булмады. Шуңа күрә дә авылдашлары ике Һашимның берсенә «Урыс» кушаматы такты. Икенче Һашимга тигән кушамат та шәплеккә шәп түгел: У...к Һашим.

Ләкин Мәдинә дә әти булган кешесенә Урыс Һашим диюләренә гарьләнә. Бу исем аның әтисен ничектер ят итеп күрсәтә сыман. Әтиләренә шундый исем таккач, балаларына ни димәсләр? Мәдинә башта оялды, аннан гарьләнде, соңыннан кирәк-кирәкмәгәнгә кимсетелмәс-хурланмас өчен кыргыйланды, илгәзәк табигатьле, ачык күңелле кыз баладан кырыс, чая үсмергә әверелде. Сугыш та бит әнә күпләрне бөкте. Элек күршесенә сәлам бирмәгән кайберәүләр хәзер кереп шуның чәен бер эчеп чыгар өчен генә дә бит йөз суын түгә.

Мәдинәләр дә артык тук яшәмиләр дә бит. Иншалла, сыер бозаулады. Мәдинә моңа кадәр дә савыт күтәреп күршеләренә йомышка бик йөрмәде, моннан соң инде ул бөтенләй чыкмаячак. Бик кирәк булса, әнә, әнисе Җантимере белән Биктимерен йөртсен. Алар, ике күпкән корсак, ашаудан башка бернигә ярамыйлар. Әнисе шуларны, кич булса иркәләп туймагандай, әле берсен, әле икенчесен тупылдатып сөя, әллә нинди колакка ятышсыз иркә сүзләр әйтә. Ә менә Мәдинә бары тик мал балаларын гына ярата. Идәндә йоклап яткан әнә ул бозаукай булмаса, өйнең ни яме булыр иде? Мәдинә үссә, абзаркурасын тутырып мал асрар, ә инде элегрәк туса, көтү-